**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2016 ел, 10 октябрь № 732

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Муниципаль милектә булган җирләрдә яки җир кишәрлекләрендә, шулай ук дәүләт милке чикләнмәгән җирләрдә яки җир кишәрлекләрендә стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру тәртибен раслау турында» 2016 ел, 13 август, 553 нче карары белән расланган Муниципаль милектә булган җирләрдә яки җир кишәрлекләрендә, шулай ук дәүләт милке чикләнмәгән җирләрдә яки җир кишәрлекләрендә стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Муниципаль милектә булган җирләрдә яки җир кишәрлекләрендә, шулай ук дәүләт милке чикләнмәгән җирләрдә яки җир кишәрлекләрендә стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру тәртибен раслау турында» 2016 ел, 13 август, 553 нче карары белән расланган Муниципаль милектә булган җирләрдә яки җир кишәрлекләрендә, шулай ук дәүләт милке чикләнмәгән җирләрдә яки җир кишәрлекләрендә стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2.2.1 пунктта «2.6» саннарын «2.5» саннарына алмаштырырга;

2.2.4 пунктка түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә:

«Ике яки күбрәк гариза булган очракта стационар булмаган сәүдә объектын урнаштыруга шартнамә сатулар нәтиҗәләре буенча төзелә.»;

2.2.5 пунктка түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә:

«Ике яки күбрәк гариза булган очракта стационар булмаган сәүдә объектын урнаштыруга шартнамә сатулар нәтиҗәләре буенча төзелә.»;

2.2.6 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.2.6. Стационар сәүдә объекты милекчесе (арендаторы) стационар булмаган

сәүдә объектын, шул исәптән җәмәгать туклауны объектын урнаштырган очракта, әгәр әлеге стационар булмаган сәүдә объекты, шул исәптән җәмәгать туклануы объекты урнашкан бина, төзелеш, корылма булган җир кишәрлеге белән чиктәш җир кишәрлегендә стационар булмаган сәүдә объекты урнаштырылса.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2016\732.docx